**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**«ЯҢА АЛЕКСАНДРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ**
**БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**III ЧАКЫРЫЛЫШ**

**ИЛЛЕ БЕРЕНЧЕ СЕССИЯСЕ**

**№ 1 КАРАР**

Яңа Александровка авылы 2019 елның «12» ноябре

«Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетыннан
Бөгелмә муниципаль районы бюджетына
җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча
җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда
барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен
финанслашу максатларында субсидияләр бирү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә
Яңа Александровка авыл җирлеге Советы
карар чыгарды:

1. «Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Бөгелмә муниципаль районы бюджетына субсидияләр җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Бөгелмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бирелә (алга таба – субсидияләр).

2. Субсидияләр Чираттагы финанс елына һәм план чорына «Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турында Яңа Александровка авыл җирлеге Советы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүче - Яңа Александровка авыл җирлеге башкарма комитеты.

4. Бөгелмә муниципаль районы бюджетына субсидияләрне бүлү Чираттагы финанс елына һәм план чорына «Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турында Яңа Александровка авыл җирлеге Советы карары белән раслана.

5. Субсидияләр бирү максатлары һәм тәртибе Яңа Александровка авыл җирлеге башкарма комитеты һәм Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты арасында төзелгән килешү нигезендә билгеләнә.

6. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) субсидиянең максатчан билгеләнеше;

б) субсидия бирү һәм тоту шартлары;

в) субсидия бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) субсидия күчерү графигы.

7. Килешүгә Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе һәм Яңа Александровка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе кул куя.

8. Субсидияләр Яңа Александровка авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль органнары исәбенә, килешүдә билгеләнә торган срокларда бюджет үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган акчалар исәбенә күчерелә.

9. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын законнар нигезендә Бөгелмә муниципаль районының финанс органы контрольдә тота.

10. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»челтәрендә урнаштырырга.

11. Әлеге карар рәсми халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

12. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Яңа Александровка авыл җирлеге**
**башлыгы** **Е.Г. Гыйрфанова**